САНАГАННЫ ЯРАТА

Киеренке чорда акчаны ничек итеп сак тотарга?

> 2

БЕЗ БЕРГӘ

Бу юлы да волонтерлар ярдәменнән башка булмый

> 2

РЕНАТ ВӘЛИУЛЛИН:

«Гамьсез яки иренеп яшәү ярамый!»

> 3

ФИН СУГЫШЫ

1939–1940 еллар низагында Татарстаннан да корбаннар күп була

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 38 (28811) | Шимбә | 19 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ – ЭШМӘКӘРЛӘРГӘ:

«СЕЗ – ҮЗ ТӨБӘКЛӘРЕГЕЗДӘГЕ ҖИТӘКЧЕЛӘРГӘ ТЕРӘК»

Аралашырга, бердәмләшергә һәм ярдәмләшергә. Россиянең 40 төбәгеннән килгән 500гә якын авыл эшмәкәре Казаннан әнә шундый теләк белән кайтып киткәндер. Өч көн дәвам иткән X Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены кабаттан иң абруйлы, татар авылларын саклап калуга көчен һәм матди байлыгын кызганмаган кече һәм урта бизнес вәкилләрен җыйды.

tatarstan.ru

Булдыклы, тырыш фермерларның продукцияләре белән «Татар базары» күргәзмә-ярминкәсендә дә танышырга мөмкин иде. Тәм-томнар, ит һәм сөт ризыклары, бал, матур яулыклар һәм шәлләр, төрле кул эшләнмәләре белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та танышып чыкты.

Кунакларны пленар утырышта Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев сәламләде:

– Чит ил икътисады эшчәнлегендә дә, продуктларны экспортлау өлкәсендә дә авырлыклар килеп чыкты. Алдыбызда мөһим бурычлар тора. Сәүдә һәм икътисади төбәкара элемтәләрне ныгыту, дөнья базарына чыгу белән бәйле булган чыгымнарны компенсацияләү. Бергәләп без барлык авырлыкларны да җиңә алабыз. Халык арасыннан чыккан булдыклы кешеләр яңача эшли башладылар. Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены шундый милләттәшләребезне табып, аларны туплап, мөһим мәйданчыклар булдырды. Без очрашабыз, җыелышабыз, сөйләшәбез һәм тәҗрибәләрне үзебезнең эштә кулланабыз.

Җитәкче фикеренчә, эшмәкәрлек хәрәкәте җәелә барган саен район хакимиятләрендә яңа бурычлар куела.

– Нинди генә җитди бурычлар куелса да, эшмәкәрлекне үстерү буенча районнар арасында аерма зур. Аларны тарату, эш нәтиҗәлелеген күрсәтү өчен бу – яхшы резерв. Соңгы елларда авыллар картая. Әлбәттә, искелеккә корылган авыл тормышы яшьләрне җәлеп итә алмый. Ә эшмәкәрлек ул – яңалык. Яшьләрне авылларда төпләндерергә телибез икән, бердәнбер юл: заманча яшәү мөмкинлекләрен тудыру. Аның өчен күп хезмәт куярга кирәк, – диде Васил Шәйхразыев.

Ярдәмләшү исә сүздә генә калмады. Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура әгъзасы, Төмән өлкәсендәге вәкиле Ринат Насыйров өч эшмәкәрнең берәр млн сум күләмендә акча җыешуын әйтте һәм Президенттан аларны Украинадагы милләттәшләребезгә тапшыруны сорады. Залдагы башка эшмәкәрләрнең дә алар үрнәген кабатлавын үтенде.

– Безнең дин кардәшләребез читтә, Украинада авыр хәлдә калды, – диде ул үз чыгышында. – Без, татарлар – төрле җирләргә таралган халык. Беркайчан да үзебезнекеләрне ярдәмсез калдырырга тиеш түгел. Шуңа күрә, Рөстәм Нургалиевич, эшмәкәрләребезнең ярдәмен аларга җиткерсәгез иде.

Башка төбәкләрдән килгән эшмәкәрләрне Рөстәм Миңнеханов та сәламләде. Һәм авыр вакытлар булуга карамастан, аларга таянып булуына ышанычын белдерде.

– Җиңел вакытлар түгел. Әлбәттә, без үз илебез, Президентыбыз белән булырга тиеш, шик юк. Сезнең белән күрешкәч, барлык авырлыклар югалып калды. Һәммәгез дә үрнәк, үз тормышыгызны үзегез алып барасыз. Бүген яңгыраган һәр чыгыш үзе бер китап язарлык. Шундый милләттәшләребез булганда, динебез, милләтебез өчен борчылмыйбыз, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Россия эшмәкәрләренең мөстәкыйль, җаваплы булуын ассызыклады.

– Сез – үз төбәкләрегездәге җитәкчеләрегезгә терәк. Кемнәндер ярдәм көтмисез, үзегез үрнәк күрсәтеп, ярдәм итеп, күп кенә җирләрдә андагы хуҗалар өчен ышанычлы терәк булып торасыз. Мәчетләр, мәктәпләр, биналар – барысы да сезнең хезмәт, сезнең кебек эшмәкәрләр белән күтәрелә, – диде Президент.

Ул эшмәкәрләрнең балаларны дөрес тәрбияләү, гореф-гадәтләрне, телне, динне ярату үрнәге булуларын ассызыклады.

– Әлбәттә, без Татарстанда милләтебез, динебез өчен программалар эшлибез, авылларга ярдәм күрсәтәбез. Барлык өлкәләрдә дә коллегалар бу мәсьәләләргә алай ук карамый. Очрашу мөмкинлеге булу бик яхшы. Сезне тыңлап утырдым. Нәрсәгә игътибар итәргә кирәк – үземә язып, теркәп бардым. Дөньялар тынычланыр, вакытлар бик җиңел түгел, аңа карап бернинди дә куркыныч юк. Ашарга ризыгыбыз, эшебез бар, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Гариза кабул итмиләр

Татарстанның күпфункцияле үзәкләрендә никах теркәү буенча гариза кабул итми башлаячаклар. ЗАГС идарәсе карары буенча, хәзер гаилә кору яисә аерылышу турында гаризаны бары тик идарә бүлекләренә генә тапшырырга мөмкин.

Былтыр күпфункцияле үзәкләрнең бу хезмәтеннән 1 меңнән артык кеше файдаланган. Әлеге хезмәт халык арасында артык популярлык казанмаган, шуңа күрә күпфункцияле үзәк аша гариза тапшыру эше туктатылган.

Аның каравы күпфункцияле үзәкләр карамагында кешеләр мөрәҗәгате буенча никахны теркәү турында белешмәне кабат бирү хезмәте кала.

Беркатлылыктан файдаланалар

Эчке эшләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе кырыгалдарлар саны артуын искәртә. Мошенниклар, пенсионерларның беркатлылыгыннан файдаланып, аларны дефолт белән куркыта.

Әйтик, 16 мартта Чаллыда яшәүче 87 яшьлек хатын-кызга берәү Пенсия фонды исеменнән шалтыратып, икътисади кризис турында сөйләп, акчаны алмаштырырга кирәк, дип ышандыра. Пенсионердан кулда булган акчасы турында сорашканнар. Соңрак аның янына үзен фонд хезмәткәре дип таныштырган берәү килеп, алыштырырга кирәкле акча турында аңлаткан. Ул киткәннән соң, пенсионерның 470 мең сум акчадан колак кагуы ачыкланган. Әлеге очрак буенча «Мошенниклык» маддәсе буенча җинаять эше кузгатылган.

Эчке эшләр министрлыгы белгечләре таныш булмаган кешеләрнең сүзләренә ышанырга, фатирга чит кешеләрне кертергә ярамавын искәртте. Әгәр алар нинди дә булса оешма исеменнән сөйләсә, моның дөреслеккә туры килү-килмәвен кат-кат тикшерү зарур.

Сүз уңаеннан, үзләрен суд приставы дип таныштырып, электрон почтага ялган хәбәрләр таратучы кырыгалдарлар саны да күбәйгән. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы белгечләре бу очракта да уяу булырга чакыра. Ышанып, банк картасы һәм исәп-хисап счеты турында мәгълүматларны алдакчылар кулына тапшырмаска, шикле финанс операцияләре башкармаска өнди.

Язгы ярминкә башлана

19 мартта Казанда язгы авыл хуҗалыгы ярминкәләре башлана. Аны атна саен башкаланың 15 мәйданчыгында оештырачаклар. Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә республиканың төрле районнары катнаша. Сәүдә иртәнге 6дан башланып, 12гә кадәр барачак. Шәһәр халкына арзан бәядән сыйфатлы продукцияне Казанның Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Яңа Савин, Мәскәү, Идел буе, Совет районнарындагы мәйданчыкларда тәкъдим итәчәкләр. Шулай ук «Салават күпере» торак комплексында яшәүчеләр өчен ярминкә Осиново бистәсендәге «Радужный» сәүдә үзәге парковкасында оештырылачак.

Көрәш

59 нчы сәхифә

Каһарман-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган көрәш турнирының чираттагы сәхифәсен Казанда язабыз. 59 нчы бәйгедә 47 команда һәм 370 көрәшче чыгыш ясый. Батыр исемен кемнәр алыр да иң көчлеләр булып кемнәр танылыр?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Соңгы елларда Чаллы, Әлмәт, Биектау, Зәй, Актаныш, Минзәләдә узган бәйге кабат Казанга әйләнеп кайтты. Татарның иң асыл егетләре «Ак Барс» көрәш сараенда бил алыша. Яше 60ка якынлашса да, әлеге турнирның асылы һәм мәгънәсе үзгәрми. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республиканың Көрәш федерациясе җитәкчесе Марат Әхмәтов ачылыш тантанасында әлеге турнирның көрәш тарихында дистә еллар буена үз абруен саклавын әйтте.

– Республикабызның көрәш тарихына күз салсак, Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы бәйгене иң дәрәҗәле, иң абруйлы турнир, дип атарга була. Биредә көрәшчеләрнең асылы ачыклана. «Ватаным Татарстан» газетасы инде ничә дистә еллар дәвамында үз миссиясен бик зур җаваплылык белән башкара. Бу эш дәвамлы булыр дип ышанам. Әлеге бәйгене бүген мәйдан тоткан егетләр генә түгел, элеккеге батырларыбыз да дулкынланып көтә. Татар халкының батырлыгын, горурлыгын дөньяга таныткан егетләребез – Рәшит Сәмигуллин, Габбас Әхмәдиев, Фазыл Әхмәтҗанов та биредә. Безнең көрәшчеләребез милләтебезнең йөзен, аның холкын күрсәтә. Сез – илебез, милләтебез өчен фидакарьләрчә яши һәм эшли торган егетләр. Турнир дәвамында бик матур көрәш күрербез һәм киләчәккә яхшы өметләр белән таралырбыз дип ышанам, – диде ул, көрәшчеләрне сәламләп.

Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов та, Марат Әхмәтовның сүзләрен куәтләп: «Дөрестән дә, безнең өчен зур бәйрәм бу. Көрәш кенә түгел, дуслар, фикердәшләр белән очрашу, аралашу шатлыгы да. Шуңа да без бу турнирны ел саен көтеп алабыз. Нинди генә еллар килсә дә, «Ватаным Татарстан» газетасы 59 ел элек гамәлгә куйган әлеге бәйгене дәвам иттерә, абруен төшерми. Бүген без тагын бер кат герой-шагыйребез Муса Җәлилнең батырлыгын искә алдык. Без дә егетләребезнең аның кебек көчле рухлы булуын телибез», – диде.

Ахыры 4 нче биттә >

Сүзгә-сүз

kremlin.ru

Дмитрий ПЕСКОВ, Россия Президенты матбугат сәркатибе:

Хәтерләсәгез, коронавирус пандемиясе башлангач, карабодайга ихтыяҗ артты. Тик аны күпләп сатып алу мәгънәсез гамәл булды, чөнки складта ярма бар иде. Хәзерге азык-төлеккә бәйле шау-шу – күбесенчә хисси ыгы-зыгы ул. Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы бик яхшы эшли. Билгеле, кемдер үз хис-тойгыларын йөгәнли алмыйдыр, әмма бу әле кибеткә барып, бәдрәф кәгазе, карабодай, шикәрне күпләп сатып алу өчен нигез түгел.

РОССИЯДӘ – ОНЛАЙН МОШЕННИКЛЫК

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре ачыклаганча, Россиядә яшәүчеләрнең 29 проценты онлайн сатып алу вакытында мошенниклык корбаны булган.

Җылыта!

19 мартта Татарстан территориясендәге һава температурасы – 9...–14 градуска кадәр суытачак. Урыны белән 18 градуска кадәр салкын булыр дип көтелә. Көндез исә бөтенләй башкача булачак. 19 мартта һава температурасы –3...+2 градуска кадәр җылытачак. Юлларда бозлавык саклана.

20 мартта республикада кар явачак. Төнлә һава температурасы –5...–10 градус булса, көндез 4 градуска кадәр җылытачак.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Якларгамы, акларгамы?

Россияне, эткәләп-төрткәләп дигәндәй, Европа Советыннан чыгардылар. Без дә, Советыгыз үзегезгә булсын, дигән кебек, әллә ни карышып тормадык, кул селтәдек тә чыктык. Бу гамәлнең дөрес яки дөрес булмавын якын тарих күрсәтер. Әмма чыгар-чыкмастан ук биредәге кайберәүләр, бигрәк тә ЛДПР вәкилләре: «Явыз җинаятьләр өчен үлем җәзасы кертүдән безне хәзер беркем дә тыймый, якын арада ук бу эшне эшләргә кирәк», – дигән сүзләр сөйләп алды. Халыкның да билгеле бер өлеше андый җәзаны кертү ягында. Дәүләтнең кешене, әлбәттә, ул җинаятьче булган тәкъдирдә, үтерергә хакы бармы? Кирәкме безгә үлем җәзасы?

Бу язмага керешүнең әле тагын бер сәбәбе бар. Ул үзенчәлекле юбилейга бәйле. Моннан нәкъ 230 ел элек, 1792 елның 20 мартында, Франция Милли ассамблеясы үлем җәзасына хөкем ителгәннәрне гильотина пычагы астына салырга кушкан карар чыгара. Революция дөрләгән, бер ел элек кенә, Европада беренчеләрдән булып, андый җәзадан баш тартырга җыенган дәүләттә яңа төр үлем коралын гамәлгә кертүне кыргыйлык дип бәяләргә дә мөмкиндер. Ләкин бик үк алай түгел. Чөнки Бөек Француз революциясенә кадәр, ул тарафларда Урта гасырлардан калган вәхши алым – кешенең дүрт санын дүрт якка дүрт ат белән тартуны (четвертование) да еш кулланганнар. Мәйданнарда, йөзләгән ачык авыз карап торганда. Шунлыктан һөнәре буенча табиб саналган зат уйлап тапкан, җинаятьчене газапсыз гына бакыйлыкка озатучы гильотинаны эшкә җигүне үзенә күрә бер алга китеш дип карарга да була кебек. Тик барыбер, дөньяга бөек фикер ияләрен, гуманистларны, Вольтер, Руссо кебек мәгърифәтчеләрне биргән илдә өч-дүрт метр биеклектән төшеп, мизгел эчендә бәндәне башсыз калдыручы кыек пычакның 1977 елга (!) кадәр эшләп килүе артык гаҗәп. Бары шул елда, үлем җәзасыннан баш тарткач кына, Францияне бүген 47 ил әгъза булып торган халыкара оешма – Европа Советына алалар.

Мин боларны ни өчен язам? Дин әһелләреннән шундый сүз ишеткәләгән булды: «Бер кешене үтерү дә кешелекне үтерүгә тиң». Әменә сәләтле һәм үзенчәлекле прозаик, афоризмнар авторы Зөлфәт Хәким бервакыт: «Кешенең кешене үтерергә хакы бар», – дип язган иде. Боларның кайсы хаклы соң? Шәхсән миңа соңгы караш белән килешү авыр. Кешегә гомерне Ходай бирә, аны бер Ходай гына алырга хаклы. Миңа калса, дәүләтнең дә кешене үтерергә хакы юк. Беренчедән, бу – бик җиңел котылу чарасы (таш капчыкта ул күбрәк газаплана), икенчедән, практика күрсәткәнчә, суд-мәхкәмә системасы күпчелек илләрдә һаман да камиллектән ерак: суд ялгышлары җитәрлек. Гаепсез килеш үтерелгәнне кире кайтарып булмый.

Галимнәр, юристлар, дин әһелләре, сәясәтчеләр, иҗтимагый оешмалар бар илләрдә дә диярлек әлеге мәсьәләдә һаман да бәхәстә кала. Алда әйтелгән җәзаны гамәлгә кертү яисә калдыру яклыларның да дәлилләре саллы кебек. Өлкән туган әйтмешли, «око за око», ягъни кеше җанын кыйганның Җирдә яшәргә хакы юк. Төп аргумент шундый. Җинаятьче төрмәдән качарга, берәр төрле амнистиягә эләгергә, аннан чыккач, элекке кәсебен дәвам иттереп, тагын кемнедер үтерергә мөмкин. Качмаган очракта төрмәдә кеше үтермәс дип тә булмый. Суд карарын үтәп, залимнән бөтенләйгә котылганда гына рецедив беркайчан да булмаячак. Озак еллар буе аны салым түләүче җилкәсендә тотуда да рациональлек юк.

Шулай да, язуларынча, бүген дөньяның 140лап илендә үлем җәзасы гамәлдән чыгарылган. Башкача әйткәндә, бу мәсьәләдә Европа Советының, аның таләпләренең бер катнашы да юк. Четерекле проблеманы һәр ил үз дигәнчә хәл итә. АКШ бу яктан гомумән дә башкалардан аерылып тора: иң каты җәза дигәндә, һәр штатның – үз законы. Имештер, авыр җинаять кылганнар анда, үлем җәзасыннан котылу өчен, штаттан штатка качып йөри. Үлем җәзасыннан баш тарту дигәндә, хак булса, беренче булып бу гамәлгә Исландия барган. XIX гасырның беренче яртысында ук. Шул гасырда аңа Португалия, Голландия, Норвегия кебек илләр кушылган. Без яшәгән илдә андый җәза, мәгълүм ки, 1996 елдан бирле кулланылмый.

Җинаять һәм җәза дигәндә, дөнья барыбер үзгәрә. Һәм ул үзгәреш яхшы якка дияргә мөмкиндер. Кешелеклелек дигән, кешене кыргый җанвардан аерып торган төп сыйфат сизелер-сизелмәс темплар белән булса да арта тора, вәхшилек кими. Хәзер Борынгы Римдагы кебек, дистә мең кеше бергә җыелып, гладиаторларның берсен-берсе суйганын карап ләззәтләнми. Армияләрдә децимация – сугыш кырын ташлаган өчен һәр ун сугышчының берсен үтерү дә юк. Урта гасырлардагыча, мәйдан уртасына алып чыгып, казыкка утыртмыйлар, кабыргадан да асып куймыйлар. Җинаятьләрнең гомуми саны да, бик акрын булса да, кимүгә бара, диләр...

Сүз азагында тагын Франциягә, Бөек француз революциясе елларына кайтыйк. Кайтыйк та моннан ике гасыр гына элек булган рәхимсезлекләргә шаккатыйк. Инкыйлаб лидерлары гильотинаны гуманлы, хөкем ителгән затка фанилыктан җиңел китәргә булышучы үлем машинасы санаса да, Робеспьер белән Дантонга, башкаларга аның алаймы, түгелме икәнен үз муеннарында сынарга туры килгәнен дә беләбез. Икенчедән, гуманлылык дигәндә, башка фикер дә бар. Баш, гәүдәдән аерылгач та, 10 секунд чамасы уйлау һәм күрү сәләтен саклый, диләр. Бу хәлне, ихтимал, ул заманнарда да белгәннәрдер. Палач, затсыз эш башкарылу белән, башны чәченнән алып югары күтәрә, халыкка күрсәтә торган булган. Корбан да, берничә мизгел эчендә, үлемне тамаша санап җыелган халыкны күреп калган. Жорж Дантон, имеш, палачка: «Минем башны халыкка яхшылап күрсәт, ул аңа лаек», – дип әйткән, ди. Террорга кереп киткән революционерлар андый үлемгә лаек булганмы, юкмы, кистереп әйтү бүген авыр. Һәрхәлдә, Дантонның көрәштәше Робеспьер кабере ташына: «Әй, узгынчы! Ялгышасың, әгәр кызганырга минe теләсәң. Шөкер, диеп үтче, сөен бары, мин монда ятканга син исән», – дип язылган диләр. Шулайдыр, эпитафияләр гадәттә алдашмый.

Камиләгә рәхмәт!

Президент көндәлеге

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы, Россиянең атказанган спорт остасы Камилә Вәлиева белән очрашты.

Республика җитәкчесе спортчы кызның Пекинда узган Олимпия Уеннарындагы осталыгын югары бәяләде, Камиләнең спорттагы уңышлары башка яшьләр өчен дә үрнәк булып торуын әйтте һәм «Дуслык» орденын тапшырды.

Очрашуга фигуралы шуу остасының әнисе Алсу да килгән иде. Аңа Президент «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медален тапшырды.

tatarstan.ru

Хезмәтегез өчен рәхмәт!

20 март – Торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре көне. Аларны һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин котлады.

«Бүгенге тормышны көнкүреш уңайлыкларыннан башка күз алдына да китереп булмый, – диелә котлауда. – Торак-коммуналь хуҗалык – эшкә сәләтен даими рәвештә тәэмин итеп торуны таләп иткән гаять зур система, «тере» организм ул.

Татарстанда инженерлык инфраструктурасын яңарту буенча зур эшләр алып барыла. 2022 елда торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә барлыгы 17,8 миллиард сумга 8 программаны тормышка ашыру күздә тотыла. Алар арасында – халыкны чиста су белән тәэмин итү программасы, урамнарны яктырту һәм чистарту корылмаларын яңарту чаралары. «Безнең ишегалды», күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү программаларын тормышка ашыру дәвам итә. Бу программаларның барысы да һәр кешенең тормыш сыйфатына турыдан-туры йогынты ясый.

Кадерле дуслар, тармак ветераннары! Сезнең һөнәр бөтен көчне биреп эшләүне, сабырлык һәм атнаның җиде көнендә, тәүлекнең һәр сәгатендә ярдәм итәргә әзер торуны таләп итә. Шәхсән үз исемемнән һәм республикада яшәүчеләр исеменнән уңайлы тормыш-көнкүрешебезгә зур өлеш кертүегез өчен эчкерсез рәхмәт сүзләрен белдерәсем килә! Бәйрәм уңаеннан сезгә нык сәламәтлек, гаилә бәхете, күтәренке кәеф, бәхетле имин тормыш телим!»

Урман язмышы – сезнең кулларда

21 мартта дөньяда Халыкара урманнар көне билгеләп үтелә. Татарстан урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров урманчыларны һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

«Әлеге экологик бәйрәмнең төп максаты – дөньяда яшәүчеләргә урманнарның мөһим климатик, су саклау, эрозиягә каршы, икътисади һәм социаль үзлекләре турында искәртү, аларга карата җаваплы һәм сакчыл караш кирәклеге турында җиткерү, – диелә котлауда. – Татарстан урманнары 1 миллион 268 мең гектар мәйдан били. Барлык саклагыч урман үсентеләрен дә исәпкә алып, хәзерге вакытта төбәкнең урман белән каплану дәрәҗәсе 20 процентка якын тәшкил итә.

Урман сагында барлыгы 2,5 мең кеше тора. Мин сезгә авыр, әмма намуслы хезмәтегез өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәм. Сез – югары квалификацияле белгечләр. Сезнең тырышлык нәтиҗәсендә республикада ел саен меңләгән гектарда урман утыртыла, нәтиҗәле дәүләт урман контроле гамәлгә ашырыла, урманнарны янгыннардан, корткычлардан һәм авырулардан саклау тәэмин ителә.

Республика халкына урманга битараф булмаган мөнәсәбәте һәм «Хәтер бакчасы», «Урманны саклыйк» һәм «Татарстанның чиста урманнары» табигать саклау акцияләрендә актив катнашканнары өчен аерым рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә. Сезнең һәркайсыгыз әйләнә-тирә мохитне саклауга бәяләп бетергесез өлеш кертә, урман тармагын үстерүгә, киләчәк буыннар өчен урман байлыкларын саклап калуга һәм арттыруга ярдәм итә».

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН – ВОЛОНТЕРЛАРГА:

«СЕЗНЕҢ ЯРДӘМ ҮЗЕГЕЗГӘ МЕҢЛӘТӘ КАЙТАЧАК»

Без бергә!

Ил кичергәнне алар да йөрәге аша кичерә. Бу юлы да волонтерлардан башка булмый. Татарстан парламенты җитәкчесе, «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге секретаре Фәрит Мөхәммәтшин «Без бергә!» гуманитар штабы волонтерлары белән очрашты.

– Сез – безнең яшьләрнең иң затлылары. Сезнең күңелләрегез саф. Күрсәткән ярдәмегез үзегезгә меңләтә кайтачак. Бу эшегездә мин ватанпәрвәрлек кенә түгел, тормыш мәктәбен дә күрәм, – диде Дәүләт Советы Рәисе. – «Без бергә!» хәрәкәте тормышта авыр хәлдә калучыларга ярдәм итү теләге булган кешеләрне – студентларны, эшче яшьләрне, медик-волонтерларны, өлкән яшьтәге волонтерларны, укучыларны берләштерде.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, соңгы арада битараф булмаганнарның сафлары ишәя. Ярдәм чаралары да арта. Әйтик, Россиянең 32 төбәгендә эвакуацияләнергә мәҗбүр булганнарны урнаштыру өчен 200ләп вакытлыча яшәү урыны ачылган, ил күләмендә 700дән артык кирәк-ярак җыю үзәге эшли.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, киләсе атнада Татарстаннан Донбасска кабат гуманитар ярдәм күрсәтеләчәк. Аерым алганда, бу – 7 млн сумлык дарулар. Киләсе атна азагында кием-салым, азык-төлек, башка кирәк-ярак тапшырылачак.

Татарстандагы волонтерлар арасында да тумышы белән Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан булган яшьләр бар. Әйтик, Никита Лункин Горловкада туган. 2014 елда Татарстан башкаласына күченгән. Егет җырларга ярата. Киләчәген дә республикада күрә: музыка көллиятенә укырга керергә тели.

САН

Ил буенча 2 мең тоннадан артык гуманитар ярдәм җыелган.
Күченеп кайтучыларга 59 меңнән артык волонтер, шул исәптән психологлар һәм медиклар ярдәм итә.
«Кызыл Хач»ның бердәм счетына 38 млн сум акча кергән.
Татарстанда барлык дәрәҗәдәге депутатлар, «Бердәм Россия» активистлары, партия тарафдарлары 3,5 млн сумнан артык акча җыйган.

Гуманитар ярдәмне «Маяковский» үзәгендә урнашкан штабка тапшырырга мөмкин. Адресы: Маяковский ур., 24а йорт.

ҺӘР ТИЕН ИСӘПТӘ ЧАК

КРИЗИС ЧОРЫНДА АКЧАНЫ НИЧЕК ЯНГА КАЛДЫРЫРГА?

Итәк-җиңнәрне җыяр чак. Бүген Россиядә яшәүчеләрнең күпчелеге, айлык чыгымнарын киметеп, булган акчасын «кара көн»гә калдыру ягын карый. Мондый мөмкинлеге булмаучылар исә, киләчәктә кесә ягы такырая калса, ни эшләрмен, дип баш вата. Шул рәвешле килеп туган вазгыять акча санарга да өйрәтә.

Финанс тикшеренүләре агентлыгы тарафыннан уздырылган соңгы сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, ил халкының яртысыннан артыгы якын киләчәктә бик зур матди кыенлыклар кичерергә туры килмәгәе дип куркып яши. Шул сәбәпле күпләр, айлык чыгымнарын киметеп, өстәмә керем чыганаклары эзли башлаган. Араларында күп кенә гадәтләреннән баш тартучылар да бар. Тикшеренүдә катнашучыларның 25 проценты, ул-бу була калса, «кара көн»гә дип җыйган акчасын тотачагын әйткән. Ярдәм сорап якыннарына мөрәҗәгать итәргә җыенучылар, булган милкен сату турында уйланучылар да бар.

Акча җиткерү белән бәйле мондый шик-шөбһә, куркулар бездә даими рәвештә булып тора үзе. Ике елга сузылган пандемия чорында да күпләр әнә шундый халәттә яшәде. Шулай да соңгы тапкыр 2014 елда күзәтелгән икътисади кризис вакытында халык акчасы, матди хәле өчен бу дәрәҗәдә үк борчылмады, дип ышандыра Финанс тикшеренүләре агентлыгы белгечләре. Һәрхәлдә, шул чорда уздырылган тикшеренү вакытында бу уңайдан борчылучылар саны 40 процентка азрак булган.

Финанс белгече Ләйсән Халикова моңарчы финанс белемен арттыру турында уйлап та карамаган кешеләргә бу хатаны төзәтү өчен менә дигән чор җитте дип саный. «Әгәр сез моңарчы финанслар белән бик дус булмагансыз икән, хәзер бу мәсьәләне кулга алырга вакыт. Беренчедән, сезгә керем-чыгымнарны төгәл барларга кирәк. Шул вакытта гына күпме акчаның янга калуын төгәл күрә аласыз. Алга таба ни эшләргә икәнен дә шуннан чыгып кына ачыкларга мөмкин», – ди ул.

Белгеч сүзләренә караганда, бүгенге белән генә яшәмичә, киләчәк турында да уйланган һәркемдә финанс мендәре булу зарур. Фәлән әйбер сатып алырга дип җыелган акча түгел бу, кеше эшен югалткан, сәламәтлеге какшаган очракта кулланыла торган акча. Гаиләле кешеләр өчен аның күләме ким дигәндә алты айлык чыгым зурлыгында булырга тиеш. Әйтик, кеше аена уртача 20 мең сум керем алып яши икән, шуны алтыга тапкырларга кирәк булып чыга. Димәк, өйдә сезнең әнә шул кадәр суммада артык акча булырга тиеш. «Элегрәк без бу акчаның бер өлешен банкта сакларга киңәш итә идек. Әмма хәзерге вазгыятьтә аны өйдә саклавың хәерлерәк. Финанс мендәренең бер өлешен валютада да сакларга мөмкин», – ди Ләйсән Халикова.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

pixabay.com

КИҢӘШ

- Кеше булган акчасын теләсә нәрсәгә тотмасын иде. Ник дигәндә, кибетләрдәге хәзерге ыгы-зыгыны үзебез үк тудырабыз. Сорау арткан саен, бәяләр дә үсә. Кешенең теге яки бу әйберне теләсә кайсы бәягә алырга әзер икәнен күреп торган сатучы бәяне арттырачак кына, билгеле. Импорт товарлар киштәдән югалган очракта да, аларны үзебездә җитештерелгәннәре алмаштырачак. Шуңа күрә, шаукымга алданып, болай да санаулы гына булган акчаны әрәм-шәрәм итәргә кирәкми.
- Өстәмә керем чыганагы табу да зыян итмәс.
- Азык-төлек алырга кибеткә барыр алдыннан башта махсус кушымта аша сезгә кирәкле әйбернең төрле кибетләрдәге бәяләрен чагыштырып карый аласыз. Бу да шактый акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә.
- Йортыгызда иске кием-салым, тотылмаган савыт-саба, кирәкмәгән башка кирәк-яраклар булса, аларны махсус сайтлар аша сатарга да мөмкин.

БИТЛЕК ТӨШМӘСЕН ЙӨЗДӘН

COVID-19

Татарстанда битлек кию режимы белән хушлашырга җыенмыйлар. Кафе-рестораннарга төнге сәгатьләрдә эшләргә ярамый. Әлегә. Вазгыять тотрыклана дип фаразлап булмыймы әллә?

kzn.ru

Саннар башкасын сөйли. Әйтик, узган тәүлектә республикада коронавирус белән авыручылар саны 458 кеше булган. Бу инде инфекция белән чирләүчеләр саны 2,2 тапкыр кимегән дигән сүз.

Мондый вазгыять республика хастаханәләрендә вакытлыча ачылган йогышлы авырулар госпитальләрен ябарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, бу атнадан Республика клиник хастаханәсе базасындагысы эшләвеннән туктый. Билгеле, коронавирустан дәваланучылар сәламәтләнеп беткәч. Яңа сырхауларны Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсенә озатачаклар.

Сүз уңаеннан, коронавируслы сырхаулар өчен Татарстанда 1514 ятак булдырылган. Госпитальләрдә шуларның 10 проценты файдаланылмый.

Мәгълүм булганча, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе битлек кию режимын бетерде. Татарстан да алардан үрнәк алачакмы? Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина, әлегә юк, ди.

– Коронавирус белән авыручылар саны кимүгә карамастан, республика битлек киюдән баш тарту турында уйламый. Федераль нормалар бар. Алар үзгәрү белән, бу сорауга әйләнеп кайтачакбыз. Шулай ук кафе-рестораннарның төнге сәгатьләрдә эшләвен дә рөхсәт итә алмыйбыз, – дип аңлатты ул.

Хәзер күпләр коронавирусның яңа штаммы хакында сүз куерта. Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков сүзләренчә, аның турында мәгълүмат бик аз. Шуңа күрә аның үзенчәлекләре турында сөйләргә иртәрәк.

Яңасы турында уйлаганчы, элеккеләрен йоктырмас, иммунитет саклансын өчен вакцина әһәмияте турында искә төшерде белгеч. Аның сүзләренчә, март һәм апрель айлары – коронавируска каршы профилактик чаралар оештыру өчен иң кулай вакыт.

– Хәзер бездә тотрыклырак вазгыять саклана. Шулай булгач, март һәм апрель айларын коронавируска каршы вакцина ясату һәм ревакцинация өчен файдаланырга кирәк, – дип киңәш итте Владимир Жаворонков.

Сүз уңаеннан, ревакцинацияне мәҗбүри итәргә дә мөмкиннәр икән. Любовь Авдонина, монысын инде вакыт күрсәтер, диде. «Күмәк иммунитетны куәтләп тору өчен, вакцина ясатып торырга кирәк», – дип искәртте идарә белгече.

РЕНАТ ВӘЛИУЛЛИН:
«ТЕЛДӘН, МИЛЛӘТТӘН ВАЗ КИЧЕП БУЛМЫЙ»
ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТКӘРЕ ПОРТРЕТЫНЫҢ КАЙБЕР ЧАЛЫМНАРЫ ТУРЫНДА

«Компетенция» татарча киң мәгълүматлы булу дигән сүзне яки тагы бер мәгънә – учреждениенең яки аерым кешенең эш йөртүгә хакы булган мәсьәләләре, өлкәсе, мәйданы дигәнне аңлата. Татар телен белү дә компетентлык билгесе булып хезмәт итә. Бу лингвистик әзерлек – туган телне белү – дипломатиягә, икътисади-мәдәни хезмәттәшлеккә турыдан-туры бәйле булып чыга.

piter.tatar

Татарстанның чит илләрдә һәм Россия төбәкләрендә 21 даими һәм тулы хокуклы вәкиле эшли. Аларның һәркайсы республиканың йөзе булып хезмәт итә һәм мөһим юнәлешләрдә эш алып бара. Бүген шул 21 вәкилнең берсе – Россиянең төньяк-көнбатыш төбәкләрен багучы Ренат Вәлиуллин турында сөйләп, аның үрнәгендә үзебезнең компетентлыкны көчәйтербез.

19 мартта 50 яшен тутыручы Ренат Нәкыйф улы Вәлиуллин – Казан университетында диплом алган һөнәре буенча филология һәм тарих белгече, татар теле, әдәбияты, тарих укытучысы.

Соңгы 7–8 ел дәвамында Ренат Вәлиуллин, Татарстанның Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсе буенча даими вәкиле буларак, икътисади һәм гуманитар элемтәләрне киңәйтү, татарларның милли-мәдәни тормышына ярдәм итү белән шөгыльләнә. Төньяк-көнбатыштагы Архангельск, Вологда, Калининград, Киров, Новгород, Мурманск, Псков өлкәләре шулай ук 3 Балтыйк буе иле белән Татарстанның элемтәләре дә аның вәкаләтенә керә.

Татар мәркәзе Казанга терәлеп торган «чеп-чи» татар авылында (Арча районы Урта Сәрдә авылы. – **Ред.**) туып-үскән егетнең татар факультетын тәмамлап, татар китабы һәм тарихы белән, тышкы элемтәләр белән шөгыльләнүе очраклы түгелдер. Ренат Вәлиуллин белән шул турыда сөйләшәбез.

– Мин Санкт-Петербургта күбрәк рус мохитендә яшим, эштә русча да, татарча да сөйләшергә туры килә. Чишмә башы, тамырлар, балачак, туган телдә генә аралаша торган туган авыл, туган йорт бар, тормыш шуннан башлана. Кыен хәлләр килеп чыкса, арып китсәм, авылга, туган йортка, туган тел мохитенә кайтып, «аккумулятор»га көч һәм энергия тутырам. Хәтта 2–3 көндә яңарып, көч-хәл туплап киләм.

Туган ягым, әти-әнием, остазларым белән горурланам. Фәнни хезмәтемнең җитәкчесе Әбрар Кәримуллин, Миркасыйм Госманов, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мөхәммәт Мәһдиев кебек олуг әдипләр белән аралашу искиткеч рухи байлык, гыйлем бирә иде. Әбрар абый белән соңгы көннәренә кадәр очрашып тордык, шифаханәдә ятканда, гомере өзелергә торганда да аның зиһен-акылы төгәл булды, әйтер сүзләре бар иде.

:: 1917 елга кадәр йөзләрчә татар газета-журналлары басылган. Ә дәреслекләр күпме чыккан икән? Ул вакытта мәдрәсәләр дәүләт ярдәменнән башка эшләгән дип чамаларга була. Дәреслекләр дә татарлар хезмәте нәтиҗәсе булгандыр?

– Әлбәттә. Төрле чыганакларны өйрәнеп, мин дәреслекләрнең исемлеген төзедем. Бу эш хәзер дә дәвам итә. Ял көннәрендә, эштән соң китапханәгә, архивка бару гадәткә керде. Санкт-Петербург Россия империясенең башкаласы булгач, монда барлык китапларның, дәреслекләрнең үрнәк экземплярлары җибәрелгән. Минем фәнни хезмәтне дәвам иттерү өчен монда шартлар яхшы. Хәзергә минем исемлеккә 1000нән артык дәреслек керде. Бу эш тәмамланмаган, аны дәвам иттерергә телим. Мәдрәсәләр эшчәнлеген, дәреслекләрне тулысынча өйрәнгәч, дәреслекләр исемлегенең саны тагын да артыр дип фаразлыйм.

:: Татарстан вәкиллегендә милли тарих, мәдәният мәсьәләләре еш күтәреләдер?

– Әйе. Чөнки бу Россиянең башкаласы булган шәһәр бит. Мәдәни башкала, диләр. Шулай булгач, татар мәдәнияте, тарихы, татар теле һәрвакыт игътибар үзәгендә. Гуманитар тема, вәкиллек ачылгач, беренче еллардан башлап ук аерым урын алып торган. Бигрәк тә Россия тарихы, дәүләт эшләрендә татар шәхесләренең тоткан урыны элекке елларда ук кызыклы нәтиҗәләр бирде. Миңа кадәр даими вәкил булган Шамил Камил улы Әхмәтшин – Россия империясе тарихы буенча тәҗрибәле тарихчы һәм дипломат. Ул кызыклы проектлар тормышка ашырган иде. Шулай ук безнең күренекле төбәкне өйрәнүче Рәхим Теләшов Петербург татарлары турында зур монография чыгарды. Бүген Санкт-Петербургта 40 татар профессиональ рәссамы эшли, аларның күргәзмәләрен даими рәвештә Татарстанда, Башкортстанда, Кырымда, үзебез дә күргәзмәләр оештырып торабыз. Күренекле скульпторларыбыз Әхнәф Зиякаев, Венера Абдуллинаның эшләре инде күпләргә таныш.

:: Питер татарлары 12 оешмага йөри, диләр. Аларны килештерү өчен кемнәрнедер үстереп, кайберләрен туры юлга юнәлтеп торырга туры киләдер...

– Алай димәс идем. Вәкиллек барлык оешмалар белән эшләргә, тигез мөнәсәбәттә булырга тырыша. Кемнәр конструктив игелекле эшләрне күбрәк башкара, шулар белән күбрәк эшләргә, ешрак очрашырга туры килә. Милли чаралар, татар мәдәнияте бәйрәмнәре кызыклы үтә бездә.

Иң беренче чиратта татар милли-мәдәни автономиясе, «Файда», «Мирас», «Изге юл», «Ак калфак» татар оешмалары актив эш алып бара, без аларга даими ярдәм итеп торабыз. Равил хәзрәт Пончаев җитәкчелегендәге Җәмигъ мәчетен «татар мәчете» дип йөртәләр. Анда дини чаралар милли эшләр, туган телне өйрәнү бергә үрелеп башкарыла. Өч урында татар якшәмбе мәктәпләре эшли. Шулай ук төрле чаралар, Сабантуйлар үткәрүгә Питерда яшәүче эшмәкәрләребез даими ярдәм итеп тора.

Петербургның Хәсән базарында Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Азнакай районы хакимияте ярдәме белән «Татарский дворик» сәүдә йортын эшләтеп җибәрә алдык. Республикада җитештерелгән 150 төрле азык-төлек товарлары монда сатыла.

Ике ел элек Татарстанның Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеге тәкъдиме белән piter.tatar дигән интернет порталы ачып җибәрелде. Узган гасыр башында чыга башлаган беренче татар «Нур» газетасының миссиясен талантлы компьютер белгече Равил Закиров алып бара. Аның piter.tatar интернет порталы коммуникация чарасы гына түгел, татар милли хәрәкәтенең заманча формасы дияргә була. Милләттәшләрнең бу портал тирәсендә туплануында РФ төбәкләре, чит ил татар яшьләре дә катнашалар.

:: Хәзерге чорда Петербург татарларының милли тормышы, Татарстан белән бәйләнешләр канәгатьләнерлекме?

– Хәзерге көндә төньяк башкалада тулы канлы татар тормышы бара дип әйтер идем. Татарстан белән хезмәттәшлек, республикабызның мәдәни тәэсире уңай бәяләнә. Җәмәгатьчелек тә канәгать. Шәһәр җитәкчелеге 300 квадрат метр мәйданлы матур бинаны татар мәдәни үзәгенә арендага бирде. Димәк, татарларның җыелып аралаша торган, мәдәни очрашулар, күргәзмәләр урыны бар. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов ярдәменә Питер татарлары рәхмәтле. Петербургта һәм башка төбәкләрдә эшләүче вәкиллекләр канат җәйгәч, Татарстан тагы да зуррак, көчлерәк булып күренә. Һәм бу чыннан да шулай.

:: 50 яшь тулу уңаеннан нинди хисләр кичерәсең? Башкарган эшләрең планнарга тәңгәл киләме?

– Илле яшь дип йомгак ясау теләге юк миндә. Акыл керә торган чак җитте. Телдән, милләттән ваз кичеп булмый. Шул хакыйкатьне яшьрәкләргә, гомумән, милләттәшләргә аңлатасы, заманча дәлилләр китерәсе килә. Тормыш печәне шактый киң «покос» белән чабыла. Алда торган бурычлар, эшләнмәгән эшләр тагы да күбрәк, җитдирәк булып күренә. Хәзерге шартларда туган телебез, милләтебез, республикабыз саклансын, алга барсын өчен башкарасы эшләр бик күп. Шуңа күрә гамьсез яки иренеп кенә яшәү ярамый дип уйлыйм.

Римзил ВӘЛИЕВ

ВТ

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:
I урын – 10 мең сум;
II урын – 7 мең сум;
III урын – 5әр мең сум күләмендә ике премия.
Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:
«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222-09-70, 8 917-927-00-40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында. 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә. Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама. 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан шәһәре 9 нчы стоматология сырхауханәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сабиров** Азат Наил улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының икътисади куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү идарәсе Чаллы шәһәре, Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә һәм Тукай районнары буенча бүлеге (Чаллы шәһәрендә урнашкан) башлыгы, полиция полковнигы **Абдрахманов** Фаяз Әсхәт улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциячел булмаган оешмасы идарә рәисенең гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары **Бикбов** Ренат Роберт улына, Мамадыш районы кулланучылар җәмгыятенең производство мөдире **Иванова** Светлана Владимировнага, «ӘНӘК» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ашханәсе мөдире (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Нуртдинова** Хәлимә Сәлимҗан кызына, Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе ваклап сатуга чыгарылган алкоголь продукциясенә контроль бүлеге башлыгы **Солуянова** Елена Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп өч елга түбәндәгеләрне сайларга:
Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
10 нчы суд участогына – Акимова Елена Андреевнаны;
Татарстан Республикасы Чистай суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Касаткина Инна Владимировнаны.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп чикләнмәгән вакытка түбәндәгене сайларга:
Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Гыйлемханова Резеда Илдар кызын.
3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә сайланган Гыйлемханова Резеда Илдар кызының Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вәкаләтләре чоры элеккеге вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 16 марты
№ 1363-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утызынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утызынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:
1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция эшчәнлеге турында 2021 елгы хисабы.
3. «2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.
4. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2021 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматы.
5. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2021 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсешенә керткән өлеше хакында хисап.
6. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 272-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 274-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» 279-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 282-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләр турында» 266-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
11. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 275-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары урыннарын булдыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 280-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 281-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 268-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Һөнәр берлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 276-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Хезмәтне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 277-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
17. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 273-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 61739-8 номерлы федераль закон проекты хакында (социаль-икътисади үсеше алга киткән территорияләрнең исемен үсеше алга киткән территорияләргә алмаштыруга бәйле рәвештә).
19. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 11^1 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 74544-8 номерлы федераль закон проекты хакында (диңгездәге файдалы казылмаларның яңа чыганакларына салым салуны камилләштерү турында).
20. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 251 һәм 262 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 71616-8 номерлы федераль закон проекты турында (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә мөлкәт хокукы рәвешендәге керемнәргә карата оешмалар табышына салым буенча ташламаларның гамәлдә булуын яңарту өлешендә).
21. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законның 2 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 68371-8 номерлы федераль закон проекты хакында (дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының яисә аларга ведомство буйсынуындагы органнарның рәсми битләрен булдыру өлешендә).
22. «Концессия килешүләре турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 75205-8 номерлы федераль закон проекты хакында (концессия килешүе, дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүләр төзү өлешендә).
23. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм урта һәм кече эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне аерып алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 1065429-7 номерлы федераль закон проекты хакында (күчемле мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибен урнаштыру өлешендә).
24. «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында (күпфатирлы йортта энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чаралары өлешендә)» 1077816-7 номерлы федераль закон проекты хакында.
25. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 16 марты
№ 1362-VI ДС

Көрәш

Илдар Мөхәммәтҗанов

59 нчы сәхифә

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Газетабызның баш мөхәррире Гөлнара Сабирова исә егетләргә, батырлыкларын тыныч тормышта гына расларга язсын, дип теләде:

– Вакытлар узса да, чорлар алышынса да, беркайчан үзгәрми торган кыйммәтләр бар. Татар халкы өчен көрәш – спорт чарасы гына түгел. Ул – безнең яшәү мәгънәбез, асылыбыз. Ә 59 ел элек, «Социалистик Татарстан» – бүгенге «Ватаным Татарстан» газетасы әлеге турнирны гамәлгә куйганда, аны Муса Җәлил исеме белән атавы юкка гына түгел, билгеле. Каһарман шагыйрь иҗатындагы «үҗәтлек», «Ватанга тугрылык», «намус», «батырлык» төшенчәләре һәр чорда, бүген исә бигрәк тә актуаль. Ә көрәшчеләребез – безнең бүгенгебез, ышанычыбыз, милләтебез сакчылары. Бүген без бирегә элеккеге җиңүчеләрнең истәлеген яңартырга, яңа батырларны ачыкларга җыелдык. Бүген дә, киләчәктә дә тугрылык һәм батырлыкны тыныч тормышта һәм келәмдә генә расларга язсын. Инде киләсе елда буласы юбилей турниры турында хәзердән уйлана башладык, – диде ул.

Бу юлы да, яңа батырларны ачыклар алдыннан, көрәш тарихында якты эз калдырган асыл егетләр искә алынды, узган ел үзләрен яхшы яктан гына таныткан көрәшчеләр һәм аларның тренерлары бүләкләнде. Иң яхшы командалар исемлегенә Әлмәт, Кукмара, Чаллы, Балтач, Казанның Яңа Савин районы, Арча командалары керде. Иң яхшы тренерлар дип Ильяс Билалов, Җәүдәт Хөсәенов, Илнур Хәйбуллин, Руслан Нургалиев, Таһир Әхкәмов, Айрат Миңнегалиев бүләкләнде. Иң яхшы көрәшчеләр сафына Ренас Кәлимуллин, Радик Сәлахов, Раил Сәлахетдинов кертелде.

Быелгы батырлар шимбә көнне ачыклана. I урынга – 50 мең, II урын өчен – 40 мең, ике III урынга 30ар мең сум күләмендә акча бирәчәкләр. Узган ел барлыкка килгән матур традицияне дәвам итеп, финал ярышында иң яхшы көрәш алымнары күрсәткән егеткә Ильяс Галимов исемендәге махсус премия дә тапшырылачак. Аның күләме – 30 мең сум.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Уены-чыны бергә

Кемгә – бәла, кемгә – табыш

Бәла-каза килгәндә үзенә файда-табыш алып калырга теләүче кешеләр дә баш калкыта. Хәтерләсәгез, коронавирус пандемиясе башланган чорда күпләр бу афәттән «коткару чаралары»н сатты. Кызганыч, ышанучысы булганда, сатучысы да табыла инде аның.

Ил кичергән хәзерге киеренке чорда да бар андыйлар. Аларны ерактан эзлисе юк. «Авито» ише онлайн игъланнар сайтын ачу да җитә.

Бу арада бар халык кибет киштәләрен бушатып, ыгызыгы тудырып, кирәккә-кирәкмәгәнгә азык-төлек сатып алып калырга тырышты. Әйтик, Тверь шәһәрендә яшәүче берәү 12 төргәк бәдрәф кәгазен 10 мең сумга сатуга куйган. «Яңа, файдаланылмаган!» – дип тә өстәгән.

«Макдоналдс» ябылуы турындагы хәбәр дә күпләрне шаккатырды. Ашамаган, күрмәгән нәрсәме инде: кешеләр, истәлек итеп сакларсыз дипме, шушы фаст-фуд челтәреннән сатып алган азык-төлекне, пластик савытларны, шикәр стикларын сатуга куя башлады. Мондый эчтәлектәге белдерүләрне Россиянең бик күп шәһәрләрендә очрады. Бәяләр дә төрле. Мәсәлән, Төмәндә ул – 1 мең сум. Шул игъланны урнаштырган кеше исә моны шаяру дип аңлаткан. Башкалар моннан кызык табып, шалтыратты, шикәрне башка вак-төяккә алмаштырырга тәкъдим итте, дигән.

«Макдоналдс» тәңкәсен сатучылар да бар. Ул фаст-фуд челтәренең Россиядәге 30 еллык эшчәнлегенә багышлап чыгарылган иде. Аны бер сатучы 50 мең сумга тәкъдим итә. Нумизматлар, бәлки, сатып та алыр, кем белә бит.

Ләкин Түбән Новгородта яшәүче берәү барысын да уздырды! Ул «Макдоналдс» пакетын… 10 млн сумга сатарга җыена. Изге ниятттән! Аның сүзләренә караганда, бу сумма авыру балаларга ярдәм итү өчен хәйрия фондына күчереләчәк.

Киләсе үзенчәлекле игълан «ИКЕА» кибете ябылганнан соң пәйда булды. Мисалга, Блохэй дигән йомшак акула уенчыгын якынча 7 млн сумга сатарга куючылар Татарстан тирәсендә дә табылды. Искәртик: бу йомшак акула уенчыгы халык арасында шактый популяр һәм үз бәясе 1500 сум тирәсе иде.

Чаллы егете Александр шулай ук вазгыятьтән файдаланып калырга уйлаган. 13 нче модель айфонын ул… 1 бүлмәле фатирга алмаштырырга тели! Айфоннарның бәяләре соңгы арада «тешли», бәлки, чынлап та, торагын телефонга алмаштыручысы да табылыр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КЫШКЫ СУГЫШ

СССР БЕЛӘН ФИНЛЯНДИЯ АРАСЫНДАГЫ КОНФЛИКТ ТАРИХКА ӘНӘ ШУНДЫЙ ИСЕМ БЕЛӘН КЕРЕП КАЛА

Кышкы сугыш 1939 елның 30 ноябреннән 1940 елның 12 мартына кадәр дәвам итә. Бу канкоешта Татарстаннан да корбаннар байтак була. Ул ни сәбәпле килеп чыга? Максаты нинди? Фин сугышында һәлак булып, сазлыкларда «хәбәрсез югалган» якташларыбызның язмышы ничек?

Шул хакта без Казан Кремлендәге Бөек Ватан сугышы музей-мемориалының өлкән фәнни хезмәткәре Михаил ЧЕРЕПАНОВ белән сөйләштек.

– 1917 елгы инкыйлабтан соң Европа картасында яңа бәйсез дәүләт – Финляндия барлыкка килә. Шул вакыттан Суоми белән Россия икесе ике төрле үсеш ала. Илебезнең Төньяк башкаласы чик буенда, Финляндиядән бары тик 30 км ераклыкта гына кала. Гитлер Германиясе һөҗүменең котылгысыз икәнен белгән Сталин Ленинградны саклау чараларын күрергә кирәклеген бик яхшы аңлый. Чөнки ара якын булу сәбәпле, шәһәрне Финляндия территориясеннән артиллерия утына тоту бик уңайлы, шуңа күрә чикне төньяккарак күчерергә кирәк була. Мәсьәләне тыныч юл белән хәл итү өчен совет ягы Финляндиягә чикне Карелия муенына таба күчерү мөмкинлеген тәкъдим итә. Әмма килешү барып чыкмый.

:: Фин сугышы ничек башлана?

– Моңа 1939 елның 25 ноябрендә Финляндия чигеннән 800 метр ераклыктагы Майнила авылы янындагы бәрелеш сәбәпче була. Фин ягыннан бу авыл артиллерия утына тотыла, нәтиҗәдә 4 кызылармияче һәлак була, 8е яралана. 26 ноябрь көнне Тышкы эшләр буенча халык комиссары Вячеслав Молотов, Мәскәүдәге фин илчесен чакырып, протест белдерә. Әмма шунысын әйтергә кирәк: сугышның башлану сәбәбе дә, максаты да тарихчылар арасында гына түгел, сәясәтчеләр арасында да бүгенгә кадәр зур бәхәсләр тудыра.

:: Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, фин сугышы кыска срокка, якынча өч атнага исәпләнә. Ни өчен ул озакка сузыла?

– 1939 елның 30 ноябрендә Совет армиясе, сугышны игълан итеп тә тормыйча, фин чигенә үтеп керә. Совет гражданнарына бу гамәл «…сугыш уты кабызучы буржуй хөкүмәтен бәреп төшерүдә Финляндия халкына ярдәм кулы сузу» дип аңлатыла. Совет хөкүмәте бу сугышны җитдигә санамый. План түбәндәгечә була. Гаскәрне кертергә. Бу 30 ноябрь көнне тормышка ашырыла. СССР контролендә тотылырга тиешле хөкүмәт төзергә. Монысына да каршылык булмый: 1 декабрьдә Куусинен хөкүмәте оештырыла. Проблемалар шуннан соң гына башлана: Кызыл армия Маннергейм дип аталган, бетон корылмалардан төзелгән көчле фин оборонасына юлыга. Документлардан күренгәнчә, совет разведкасы мондый күренештән бөтенләй хәбәрдар булмый.

:: Совет штабы сугышка әзерләнгәндә тагын нәрсәләрне күз уңыннан читтә калдыра?

– Территориянең үзенчәлекле булуы исәпкә алынмый. Финляндия тулысынча диярлек урманнардан һәм сазлыктан гыйбарәт. Мондый шартларда хәрби техниканы күчереп йөртү бик авыр була. Авиацияне куллана алмыйлар. Фронт сызыгындагы авылларны бомбага тотуның инде мәгънәсе булмый, финнар үз артларыннан яндырылган җир калдырып артка чигенә. Шактый ерак киткән гаскәрләргә дә ут яудырып булмый, чөнки алар җирле халыкка ышыкланып бара. Финнар үз артларыннан юлларны, күперләрне җимерә, бөтен җиргә мина куялар. Финляндиягә Англия, Италия, Венгрия, Швеция кебек илләр корал, азык-төлек, самолетлар белән ярдәм итә. Кыскасы, Советлар Союзы дошманны бәяләп бетерми, сугышка әзерлексез керә. Өстәвенә гаскәрләрне оештыру бик начар куела. 30 градус салкын булуга карамастан, хәрбиләр җылы кием белән тәэмин ителми. Нәтиҗәдә фин сугышы уйланылган өч атна урынына дүрт айга диярлек сузыла. Төп һөҗүм 1940 елның 11 февралендә генә башлана.

:: Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Кышкы сугыш бик күп корбаннар китерә…

– 1951 елда СССР Оборона министрлыгы төзегән исемлектән күренгәнчә, безнең яктан югалтуларның саны – 126875 кеше. Шуларның 39369ы хәбәрсез югала. Көннәр бик салкын булганга, биш кешенең берсе катып үлә.

:: Татарстан буенча саннар ни сөйли?

– Бу сугышта республикабыз 1238 улын югалта. Әмма бу эзләнүләр нәтиҗәсендә билгеле булган исемнәр генә. Фин сугышында ятып калучыларның саны күпкә артык дип исәпләнелә.

:: Шушындый корбаннар бәрабәренә эшләнгән эшләрнең нәтиҗәсе нинди?

– Мәскәүдә тынычлык килешүенә кул куелганнан соң, СССР составына Выборг (Финляндиядә зурлыгы буенча икенче шәһәр) һәм Сортавала шәһәрләре, Фин култыгындагы берничә утрау, Куолаярви шәһәренең, Рыбачий һәм Средний ярымутрауларының аерым бер өлешләре керә. Ладога күле тулысынча СССР территориясендә кала. Хәрби-диңгез флоты төзер өчен Ханко ярымутравы 30 елга арендага алына. Финляндия территориясенең 11 проценты СССР составына күчә. Ленинградтан 32 км ераклыкта булган чик сызыгы 150 чакрымга күчә.

:: Сәяси яктан караганда, мондый хәлләр безнең ил өчен эзсез үтмәгәндер?

– СССР хәрби агрессор дип игълан ителә һәм Милләтләр лигасыннан чыгарыла. Финляндия союзниклары булган Англия һәм Франция бу хәлләрдән соң СССРның Бакудагы һәм Кавказдагы нефть промыселларын юк итү планын эшли. Нәтиҗәдә совет җитәкчелегенә Иранда да чикләрне киңәйтергә туры килә. Бу адым нефть чыгарыла торган зоналарны саклап калу өчен кирәк була. Монысы инде Гитлер басып кергәннән соң 1941 елның җәендә эшләнә. Кызылармиячеләр 25 августта Тәһран шәһәренә керәләр, 1945 елга кадәр ташлап китмиләр. Димәк, көньяктагы әлеге походны Кышкы сугышның дәвамы дип әйтергә кирәк.

:: Совет хөкүмәтенә бу фин сугышы чыннан да кирәк идеме? Бәлки, кан коюны читләтеп үтәргә дә мөмкин булгандыр?

– Бу сорауга җавап бирү өчен мин Сталинның 1940 елның 17 апрелендә җитәкчеләр утырышында ясаган чыгышыннан өзек китерәм. «… кирәк иде. Финляндия белән тыныч сөйләшүләр барып чыкмагач, Ленинградның куркынычсызлыгын һичшиксез сакларга кирәк иде. Аның куркынычсызлыгы ул – Ватаныбызның куркынычсызлыгы дигән сүз. Бу шәһәрдә илебез оборона сәнәгатенең 30–35 проценты урнашканы өчен генә түгел, Ленинград ул – илебезнең икенче башкаласы…»

Минемчә, Ленинград шәһәре бары тик шушы адым нәтиҗәсендә генә 872 көнгә сузылган камалышны кичерә алгандыр. Шундый авыр көннәрдә дә аның заводларында танклар җитештерелә. Мәскәүне саклар өчен снарядлар эшләнә. Безнең якта калган Ладога күле буйлап күпме кешене эвакуацияләргә мөмкинлек булды. Сүз дә юк, корбаннар күп, әмма килеп туган шартларда бу проблеманы башкача хәл итү мөмкинлеге калмый. Совет – фин сугышы инглиз – француз блогы, шулай ук Германия белән аңлашылмаучылыклар да китереп чыгаргандыр, әлбәттә. Финляндия һәм аның союзниклары белән тыныч сөйләшүләр нәтиҗәсендә килешү төзи алсак, кем белә, мондый каршылыклар да килеп чыкмаган булыр иде. Әмма сөйләшүләр нәтиҗәсендә генә моңа ирешү мөмкин булмады. Тарихта бүген дә мондый хәлләр кабатланып тора.

Әңгәмәдәш –
Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Фин сугышында – Советлар Союзы Геройлары

Нигъмәтуллин Гафият Нурмөхәммәт улы. 1915 елда Мамадыш районының Кече Кирмән авылында туа. 1945 елның 8 маенда Берлин өчен барган сугышларда һәлак була.

Рәхимов Баки Сибгатулла улы. 1913 елда Балтач районының Түбән Кенә авылында туа. 1940 елның 3 мартында Койвисто-Бьерке утраулары өчен барган сугышларда һәлак була.

Сабиров Хафиз Сабир улы. 1910 елда Балтач районының Иске Тура (?) авылында туа. Выборг шәһәре өчен барган сугышта һәлак була.

Спирьков Степан Петрович. 1904 елда Алабуга шәһәрендә туа. Выборг өчен сугышларда катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында Казанда, Ульяндa, Загорскида хәрби комиссар булып эшли. 1982 елның 2 сентябрендә Мәскәүдә үлә.

МАНДАРИН ҮСТЕРҮЧЕ ХӘНИФӘ АПА:

«НИК ЭЛЕГРӘК УТЫРТМАДЫМ ИКӘН?»

Шөгыль

Зәйдә яшәүче Пасмуровлар гаиләсендә табын күрке – үзләре үстергән мандарин. Көньяк гөлен 2018 елда Хәнифә апага кияве бүләк итә. Хәзер хуҗабикә элегрәк утыртмавына үкенә. Баксаң, әллә ни нәзберек үсемлек түгел икән ул.

– Беренче елны мандарины вак һәм аз булды. Авыз итеп карадык та әллә ни игътибар бирмәдек. Ул елны мандарин гөленә тимәдем. Җимешләрен алгач, ул ял итә. Шул вакытта мин аны башка савытка күчердем. Чүлмәкне яфрак ябалдашларына карап сайларга кирәк. Зурга утыртсагыз, тамырлана гына ул. Күчереп утырткач, әкренләп гөл агачка әйләнде. Икенче-өченче елларда җимешләр күбәйде. Мандарин үстерү үземнең күңелемә дә хуш килде. Хәзер уйлап торам: нигә аны иртәрәк үзебез утыртып карамадык икән дим, – ди Хәнифә апа. – Мандарин агачы ел саен гыйнвар аенда чәчәк ата. Аның хуш исен иснәп туеп булмый. Быелгы мандариннарны җыеп алдым инде. Тагын бер төрле мандарин гөлем бар. Анысының сабаклары чәнечкеле-энәле. Буе 1 метр да 30 сантиметрга җитте. Әле җимеш бирергә уйламый. Әмма аның мандариннары әфлисун кадәрле булачак. Чөнки андый төр киявемдә бар. Аныкын авыз иткәч, орлыгыннан утыртып карадым. Үземнекенең орлыкларын әрәм итмәскә уйлап торам. Барысын да утыртам, кирәк кешегә бирермен.

Хәнифә апа 40 елга якын хөкүмәт эшендә эшләгән. Башта районның паспорт өстәлендә, аннан салым инспекциясендә хезмәт куйган. Ялга чыккач, бераз моңсу да була үзенә. Аннан үзенә шөгыль таба: гөлләр үстерә, яшелчәләр утырта башлый. Өендә 60 төрле гөл үсә аның.

Хәнифә апа гөлләргә атнага бер булса да шикәрле су сибәргә куша. Болай иткәндә, гөл чәчәккә тизрәк күмелә икән. Бакчадагы матурлыкны сөйләп бетерә алмый. Шуңа ул безне үзләренә җәйгә кунакка чакырды.

– Яшелчәләрне күп итеп утыртабыз. Мин һәрнәрсәне алдан өлгертергә тырышам. Иремнең 26 майда туган көне. Аның бәйрәменә кыярны өлгертәм. Суганнарым, борычларым, помидорларым да уңа. Уңышның сере – эшне ярату, – ди ул. – Гөлләргә дә, яшелчәләргә дә, мандариннарга да әллә нинди ашламалар сипмим. Халык ысулларын да кулланмыйм. Бары тик су сибәм. Мин аларны яратам. Мөгаен, шуны сизәләрдер.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 238

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.

График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+